Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районы
Түбән Өскебаш авыл җирлеге Советы

# КАРАР

20.11.2020 ел №10

«Җир салымы турында» Түбән Өскебаш авыл җирлеге Советының 2013 елның 22 ноябрендәге 26 номерлы карарының 4 пункты үз көчен югалткан дип тану хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр керту турында» 2019 елның 29 сентябрендәге 325-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Түбән Өскебаш авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. «Җир салымы турында» Түбән Өскебаш авыл җирлеге Советының 2013 елның ноябрендәге 32 номерлы карарының 4 пункты (Түбән Өскебаш авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 ноябрендәге 33 номерлы, 2015 елның 27 маендагы 24 номерлы, 2015 елның 17 ноябрендәге 14 номерлы, 2017 елның 27 июнендәге 11 номерлы, 2018 елның 31 октябрендәге 26 номерлы, 2018 елның 29 ноябрендәге 31 номерлы, 2018 елның 17 декабрендәге 33 номерлы, 2019 елның 28 ноябрендәге 22 номерлы, 2020 елның 28 гыйнварындагы 1 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, шулай ук Түбән Өскебаш авыл җирлеге торак пунктлары территориясендә махсус мәгълүмати стендларда урнаштырырга.
3. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көннән кимендә бер айдан соң үз көченә керә.

Түбән Өскебаш авыл җирлеге
башлыгы: Н.М.Мөхәммәтҗанов